**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Түбән Чыршылы торак пунктында

13 ноябрь 2020 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлегендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, хәрби хезмә үтүче гражданнардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 400 сум күләмендә билгеләргә:

2. Алынган средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
    1. Юлларны кардан чистарту
    2. Урамнарны яктыртуны карап тоту
    3. Вак таш җәелгән юлларга ремонт ясау
    4. Агачларны кисү

Лениногорск муниципаль районы
«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина